**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**СТЕПНООЗЕРСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**НУРЛАТСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423009, с. Степное Озеро, ул. Школьная,
дом 23, телефон:8(84345) 4-63-34

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**БИКҮЛЕ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ НУРЛАТ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

423009, Бикүле авылы, Мәктәп ур.,
23 йорт, телефон:8(84345) 4-63-34

ОГРН 1021605352438,ОКПО 04312541, ОКАТО 92246880000,
ИНН/ КПП 1632001635/163201001,ОКТМО 92646480


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 26» октябрь 2020 ел** **№ 1**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Илюткино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 11 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта М. Горький урамы буенча 13нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Илюткино авылында М. Горький урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2020 елның 11 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта Совет урамы буенча 14 нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Илюткино авылында Совет урамы буенча, Клуб урамы буенча, Илюткино авылындагы Җиңү урамы буенча яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Илюткино авылында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибе халык җыенын үткәрү өчен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар Җыенының этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлегенең Илюткино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан

сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Илюткино авылы чикләрендә юлларны ремонтлау (грунт-вак таш катнашмасы һәм вак таш җәю, сатып алу, ташу, җәю)

- Илюткино авылында буа территориясен төзекләндерү (плитәләр белән ныгыту, вак таш салу)

- Илюткино авылында янгын сүндерү гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру;

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына http://nurlat.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Бикүле авыл җирлеге башлыгы А.М. Шакирова